# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАГРАЖ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

**№ 156** **24.03.2025 ел**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Баграж авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында**

2002 елның 12 июнендәге "Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 25, 26 статьялары, 2007 елның 07 маендагы 21-ТРЗ номерлы, "Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Баграж авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 32 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Баграж авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Баграж авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын ун елга расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны, бермандатлы сайлау округлары схемасын да кертеп, аның график сурәте белән бергә, 2025 елның 29 мартыннан да соңга калмыйча, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән, шулай ук Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Баграж авыл җирлегендәге Сарсаз-Баграж, Урта Баграж, Югары Баграж торак пунктлары территорияләрендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча урнаштыру:

- Урта Баграж авылы мәдәният йорты бинасында, Үзәк ур., 47а йорт;
- Сарсаз-Баграж авылы мәдәният йорты бинасында, Мәктәп ур., 3 йорт;
- Югары Баграж авылы мәдәният йорты бинасында Совет ур., 4 йорт.

3. Карар басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет рәисе П.Н. Минеев

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Баграж авыл җирлеге
Советы карарына кушымта
«24» март 2025 № 156

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Баграж авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасы**

**1 нче Беренче Май бермандатлы сайлау округы**

Сайлаучылар саны – 71

Округка Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Баграж авыл җирлеге территориясенең бер өлеше керә: Сарсаз-Баграж авылы, 1 Май урамы, Мәктәп урамы.

**2 нче бермандатлы Яшьләр сайлау округы**

Сайлаучылар саны-72

Округка Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Баграж авыл җирлеге территориясенең бер өлеше керә: Сарсаз - Баграж авылы, Вахитов урамы, 2-32 номерлы йортлар (җөп як), Яшьләр урамы, 25-37 номерлы йортлар (җөп булмаган як), 1-3 номерлы йортлар, Болын урамы.

**3 нче Тукай бермандатлы сайлау округы**

Сайлаучылар саны-71

Округка Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Баграж авыл җирлеге территориясенең бер өлеше керә: Сарсаз - Баграж авылы, Тукай урамы.

**4 нче Оренбург бермандатлы сайлау округы**

Сайлаучылар саны-73

Округка Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Баграж авыл җирлеге территориясенең бер өлеше керә: Сарсаз-Баграж авылы, Оренбург урамы, 1-21 номерлы йортлар (җөпсез як), Вахитов урамы, Урта Баграж авылы, Күпер урамы, 1-30 номерлы йортлар.

**5 нче бермандатлы Үзәк сайлау округы**

Сайлаучылар саны-68

Округка Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Баграж авыл җирлеге территориясенең бер өлеше керә: Урта Баграж авылы, Үзәк урам, Яңа урам.

## 6 нчы Тынычлык бермандатлы сайлау округы

Сайлаучылар саны-66

Округка Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Баграж авыл җирлеге территориясенең бер өлеше керә: Югары Баграж авылы, Тынычлык урамы, Совет урамы, 28-36 номерлы йортлар (җөп як), Октябрь урамы, 17-25 номерлы йортлар (җөп булмаган як).

## 7 нче Октябрь бермандатлы сайлау округы

Сайлаучылар саны-65

Округка Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Баграж авыл җирлеге территориясенең бер өлеше керә: Югары Баграж авылы, Октябрь урамы, 2-26 номерлы (җөп як), 1-15 номерлы (җөп булмаган як) йортлар, Яр буе урамы, Чишмә урамы.

